УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан ш.**

__09 июня._ 2023 ел. № __29__

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең «Апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгына үзгәреш кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән мәгълүмати хезмәттәшлек регламентын раслау турында» 2006 елның 24 октябрендәге 567 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында» 2023 елның 19 маендагы 615 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсенең «Апостиль кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 30 гыйнварындагы 5 номерлы боерыгына, преамбуласында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары тарафыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Идарә җитәкчесе вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Р.Х. Әхмәтҗанов